| Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы бюджеты тарафыннан кредитлар алу | 01 03 01 00 02 0000 710 | 156 129,0 |
| Бюджетлар чараларын исәпкә алу счетларында калган чараларны үзгәртү | 01 05 00 00 00 0000 000 | -34 868,7 |
| Бюджетлар чараларының калган өлешләрен арттыру | 01 05 00 00 00 0000 500 | -384 054 562,7 |
| Бюджетлар чараларының калган башка өлешләрен арттыру | 01 05 02 00 00 0000 500 | -384 054 562,7 |
| Бюджетлар акчаларының калган башка өлешләрен арттыру | 01 05 02 01 00 0000 510 | -384 054 562,7 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының калган башка өлешләрен арттыру | 01 05 02 01 02 0000 510 | -384 054 562,7 |
| Бюджетлар чараларының калган өлешләрен киметү | 01 05 00 00 00 0000 600 | 384 019 694,0 |
| Бюджетлар чараларының калган башка өлешләрен киметү | 01 05 02 00 00 0000 600 | 384 019 694,0 |
| Бюджетлар акчаларының калган башка өлешләрен киметү | 01 05 02 01 00 0000 610 | 384 019 694,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчала-рының калган башка өлешләрен киметү | 01 05 02 01 02 0000 610 | 384 019 694,0 |
| Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары | 01 06 00 00 00 0000 000 | 186 215,8 |
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге акцияләр һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләре | 01 06 01 00 00 0000 000 | 35 551,4 |
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан акчалар | 01 06 01 00 00 0000 630 | 35 551,4 |
| Татарстан Республикасы милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан акчалар | 01 06 01 00 02 0000 630 | 35 551,4 |
| Курс аермасы | 01 06 03 00 00 0000 000 | -112,6 |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары акчалары буенча курс аермасы | 01 06 03 00 02 0000 171 | -112,6 |

| | | |
|---|---|---|
| Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | 01 06 05 00 00 0000 000 | 150 777,0 |
| Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 01 06 05 00 00 0000 600 | 150 777,0 |
| Россия Федерациясе валютасында юридик затларга бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 01 06 05 01 00 0000 600 | 9 477,0 |
| Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында юридик затларга бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 01 06 05 01 02 0000 640 | 9 477,0 |
| Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 01 06 05 02 00 0000 600 | 141 300,0 |
| Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 01 06 05 02 02 0000 640 | 141 300,0 |
| Барлык чыганаклар | | 307 476,1 |

# ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## 573. Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

### 1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 6; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 4; 2004, № 7 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2012, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның җиденче өлешендә «фәнни-тикшеренү учреждениеләрендә, югары уку йортларында» сүзләрен «фәнни оешмаларда, югары белем мәгариф оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның өченче өлешендә «фәнни-тикшеренү институтларына һәм югары уку йортларына» сүзләрен «фәнни оешмаларга, югары белем мәгариф оешмаларына» сүзләренә алмаштырырга;

3) 8 статьяда:

а) икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт Татарстан Республикасы территориясендә мәгариф оешмалары системасын, Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә тәрбияләү һәм укытуның башка рәвешләрен булдыруны тәэмин итә һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыклар вәкилләре телләрендә тәрбияләү һәм укытуны оештыруда ярдәм итә. Татарстан Республикасында гражданнар, мәгариф системасы бирә торган мөмкинлекләрдән чыгып, мәгариф турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемне Россия Федерациясе халыклары телләреннән булган туган телдә алырга хокуклы, шулай ук Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан булган туган телне өйрәнергә хокуклы.»;

б) өченче өлештә «тәрбия-мәгариф учреждениесен» сүзләрен «мәгариф оешмасын» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Белем бирү теле, телләре үзе гамәлгә ашыра торган уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың локаль норматив актлары белән Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.»;

4) 9 статьяда:

а) икенче һәм өченче өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләрен, татар һәм рус телләрендә әдәбиятны дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары кысаларында укыту һәм өйрәнү федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында татар һәм рус телләре гомуми һәм урта һөнәри белем дәрәҗәсенә туры килерлек тигез күләмнәрдә өйрәнелә.

Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган бүтән оешмаларда дәүләт телләрен һәм башка телләрне укыту һәм өйрәнү үзе гамәлгә ашыра торган уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың локаль норматив актлары белән билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.»;

б) дүртенче өлештә «фәнни-тикшеренү учреждениеләрендә һәм югары уку йортларында» сүзләрен «фәнни оешмаларда һәм югары белем мәгариф оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

5) 22 статьяның дүртенче өлешендә «урта махсус һәм югары уку йортларының» сүзләрен «һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем мәгариф оешмаларының» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; 1994, № 1 – 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3; 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 22 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгариф оешмаларында белем алучылар янгын куркынычсызлыгы чараларына мәҗбүри өйрәтелә. Мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы органнар һәм янгыннан саклау хезмәте ирекле яшь янгын сүндерүчеләр дружиналарын төзергә мөмкин.»;

2) 26 статьяның беренче өлешендә «фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык, проект һәм башка фәнни-техник учреждениеләр һәм оешмалар, шулай ук тиешле уку йортлары» сүзләрен «фәнни оешмалар һәм мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

«Һөнәр берлекләре турында» 1995 елның 18 гыйнварындагы 2303-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Та-

тарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1995, № 1; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 9 (II өлеш); 2011, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның беренче өлешендә «башлангыч, урта яисә югары белем бирү мәгариф учреждениеләрендә» сүзләрен «һөнәри белем бирү оешмаларында яисә югары белем мәгариф оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 7 статьяның беренче өлешендә «учреждениеләр» сүзеннән соң «һәм оешмалар» сүзләрен өстәргә.

**4 статья**

«Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2003 елның 6 августындагы 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 12; 2003, № 8; 2005, № 10 (I өлеш); 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның уникенче абзацында «яңа һөнәргә өйрәнергә» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алырга» сүзләренә алмаштырырга;

2) 16 статьяның дүртенче өлешендә «башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирү һәм башлангыч һөнәр, урта һөнәр, югары һөнәр һәм югары уку йортын тәмамлаганнан соңгы һөнәр белеме бирү учреждениеләрендә» сүзләрен «белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда» сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» 1998 елның 18 июнендәге 1661 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2006, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:
а) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6. Фәнни оешма – теләсә нинди оештыру-хокукый рәвешендәге һәм милекчелек рәвешендәге юридик зат, төп эшчәнлеге буларак фәнни һәм (яисә) фәнни-техник эшчәнлек

белән шөгыльләнүче фәнни хезмәткәрләрнең иҗтимагый берләшмәсе.»;

б) 7 пунктта «яисә учреждение» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 3 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 7 статьяда:

а) 1 өлештә «фәнни дәүләт учреждениесе» сүзләрен «дәүләт фәнни оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

4) 8 статьяның 3 өлешендә «югары һөнәри белеме» сүзләрен «югары белеме» сүзләренә алмаштырырга;

5) 9 статьяда:

а) статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 статья. **Дәүләт фәнни аттестация системасы»;**

б) «фәнни хезмәткәрләр квалификациясенең дәүләт аттестацияләү системасы белән тәэмин итүче» сүзләрен «фәнни хезмәткәрләр һәм фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнүче башка затлар фәнни квалификациясенең дәүләт фәнни аттестация системасы белән тәэмин ителә торган» сүзләренә алмаштырырга;

6) 10 статьяның 1 пунктындагы уналтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«өстәмә һөнәри белем алырга.»;

7) 12 статьяның 2 пунктындагы сигезенче абзацында «кадрларны профессиональ әзерләү» сүзләрен «һөнәри укыту» сүзләренә алмаштырырга;

8) 13 статьяның 4 пунктында «дәүләт фәнни оешмаларына һәм югары уку йортларына фәнни хезмәткәрләр әзерләүдә һәм аларның белгечлекләрен күтәрүдә» сүзләрен «фәнни һәм мәгариф оешмалары өчен кадрлар әзерләүдә» сүзләренә алмаштырырга.

**6 статья**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш);

2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 26 статьяның икенче өлешендә «укучылар» сүзен «белем алучылар» сүзләренә, «вакытлы хезмәттәге» сүзләрен «чакырылыш буенча хәрби хезмәт узучы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 28 статьяда:

а) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә уку-укыту программалары буенча мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләренә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының мәгариф турындагы законнары кагыла.»;

б) дүртенче өлештә «мәдәният һәм сәнгать югары һәм махсус урта уку йортларын» сүзләрен «мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем мәгариф оешмаларын» сүзләренә һәм «авыл хуҗалыгы югары һәм махсус урта уку йортларын» сүзләрен «авыл хуҗалыгы өлкәсендә уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем мәгариф оешмаларын» сүзләренә алмаштырырга;

3) 31 статьяда:

дүртенче абзацта «мәдәният хезмәткәрләрен әзерләү һәм аларны стажировкалау» сүзләрен «мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә кадрлар әзерләү» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «мәдәният өлкәсендәге ысулиятләр, уку-укыту программалары һәм кулланма әсбаплар» сүзләрен «уку-укыту программалары, методик материаллар һәм укыту-фәнни китаплар» сүзләренә алмаштырырга.

**7 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 статьясындагы 3 пунктының 2 пунктчасына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3,

№ 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3; Ватаным Татарстан, 2014, 17 май), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2) укырга кабул ителгән хезмәткәрнең, белем алуның барлык чорына;».

**8 статья**

«Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 1998 елның 21 октябрендәге 1818 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 1 – 2; 2004, № 2 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«китапханә – документларның оештырылган фонды булган һәм аларны физик һәм юридик затларга вакытлыча файдалануга биреп торучы мәгълүмат, мәдәният, аң-белем тарату оешмасы яисә оешманың структур бүлекчәсе;»;

2) 4 статьяның 3 пунктында «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

3) 8 статьяның өченче өлешендә «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

4) 12 статьяның беренче өлешендә:

а) тугызынчы абзацта «һәм башка учреждениеләре» сүзләреннән соң «, оешмалары» сүзен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа унөченче абзац өстәргә:

«мәгълүмати, мәдәни, аң-белем тарату, фәнни, белем бирү эшчәнлеген законнар, үз уставы яисә структур бүлекчәләре китапханәләр булган оешмаларның локаль норматив актлары нигезендә гамәлгә ашырырга;»;

в) унөченче абзацны ундүртенче абзац дип санарга;

5) 14 статьяның беренче өлешендәге 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) төп һөнәри уку-укыту программаларын һәм китапханә кадрларын әзерләү өлкәсендә өстәмә һөнәри программаларны гамәлгә ашыручы республика буйсынуындагы мәгариф оешмаларын булдыру һәм финанслауны, шулай ук әлеге мәгариф оешмаларына идарәне гамәлгә ашыруны;»;

6) 21 статьяда:

а) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Милли китапханәсе – милли һәм республика, Россия һәм чит илләр матбугатының төп дәүләт китап саклагычы, күп функцияле китапханә-мәгълүмат оешмасы, мәдәни, аң-белем тарату, фәнни, библиографик, методик үзәк.»;

б) дүртенче өлештә «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга.

**9 статья**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының 42 статьясындагы беренче өлешкә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; 2003, № 6; 2005, № 7 – 8; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2012, № 5 (I өлеш), «конкуренциягә сәләтле продукцияне эшләп чыгару, гамәлгә кертү һәм җитештерү белән шөгыльләнүче тикшеренү лабораторияләреннән, белем бирү учреждениеләреннән һәм үзәкләреннән,» сүзләрен «фәнни оешмалардан, лабораторияләрдән, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалардан, шулай ук конкуренциягә сәләтле продукцияне эшләп чыгару, гамәлгә кертү һәм җитештерү белән шөгыльләнүче» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**10 статья**

«Вөҗдан иреге турында һәм дини оешмалар турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) 2 пунктның бишенче абзацында «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырырга;

б) 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дини оешмалар үтенече буенча дәүләт дин белеме бирү оешмаларында гомуми белем бирү фәннәрен укытуда ярдәм күрсәтергә хокуклы.»;

2) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья. **Дини белем, дин белеме бирү оешмалары**

1. Һәркем, үзе сайлап алып, индивидуаль рәвештә яисә башкалар белән бергә дини белем алырга хокуклы.

2. Балаларга дини тәрбия һәм дини белем бирү ата-аналарның яисә аларны алмаштыручы затларның үз балаларын үз инануларына туры китереп тәрбияләү хокукына һәм баланың вөҗдан иреге һәм дин тоту иреге хокукына нигезләнә.

3. Ата-аналарның яисә аларны алмаштыручы затларның язма үтенече буенча һәм дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларында белем алучы балаларның ризалыгы булганда, күрсәтелгән мәгариф оешмалары, гамәлгә куючылары белән килештереп, мәгариф оешмасы идарәсенең коллегиаль органы карарына нигезләнеп, дини оешмага, уку-укыту программасы кысаларыннан тыш, балаларга дин гыйлемен укыту мөмкинлеге бирергә мөмкин.

4. Дини оешмалар үз уставлары һәм мәгариф турында Россия Федерациясе законнары нигезендә мәгариф оешмалары төзергә хокуклы.

5. Үзәкләштерелгән дини оешмалар үз уставлары нигезендә, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиягә нигезләнеп, уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру юлы белән дини оешмаларның руханиларын һәм дини персоналын әзерләү өчен дин белеме бирү оешмалары төзергә хокуклы.

6. Дин белеме бирү оешмалары дини оешмалар буларак теркәлергә тиеш.

7. Дин белеме бирү оешмалары дини оешмаларның руханиларын һәм дини персоналын әзерләү өчен билгеләнгән уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра һәм урта һөнәри белемнең һәм югары белемнең уку-укыту программаларын федераль дәүләт мәгариф стандартларына туры китереп гамәлгә ашырырга хокуклы.

8. Дини оешмаларның руханиларын һәм дини персоналын әзерләү өчен билгеләнгән уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы дин белеме бирү оешмалары белем турында һәм квалификация турында документлар бирәләр, аларның формасы шушы оешмалар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнә. Белем турындагы мондый документларда күрсәтелә торган квалификация аларга ия булучыларга дини оешмаларның эчке таләпләре белән белем байлыгына мәҗбүри таләпләр куелган дини оешмаларның руханилары һәм дини персоналы функцияләрен башкару хокукын бирә.

9. Уку-укыту программаларын федераль дәүләт мәгариф стандартлары таләпләренә туры китереп гамәлгә ашыручы дин белеме бирү оешмалары дәүләт йомгак аттестациясен узган затларга «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән үрнәктәге белем турында һәм (яисә) квалификация турында

документ бирергә хокуклы. Белем турындагы мондый документларда күрсәтелә торган квалификация аларга ия булучыларга, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 60 статьясындагы 8 өлешендә каралган хокуклар белән беррәттән, дини оешмаларның эчке таләпләре белән белем байлыгына карата мәҗбүри таләпләр куелган дини оешмаларның руханилары һәм дини персоналы функцияләрен башкару хокукын бирә.»;

3) 10 статьяның 5 пунктында «һөнәри дин белеме учреждениесе» сүзләрен «дин белеме бирү оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

4) 11 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Түбәндәгеләр дини оешманы гамәлгә куючы (аның катнашучысы, әгъзасы) була алмый:

Россия Федерациясендә булулары (яшәүләре) хупланмау турында карар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат;

«Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә) һәм террорчылыкны финанслауга каршы көрәш турында» 2001 елның 7 августындагы 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә исемлеккә кертелгән зат;

«Экстремистлык эшчәнлегенә каршы көрәш турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә эшчәнлеге туктатылып торган дини оешма;

үз көченә кергән суд карары белән гамәлләрендә экстремистлык чалымнары булу билгеләнгән зат.»;

5) 19 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дини йолалар шулай ук мәгариф оешмалары территорияләрендә урнашкан дини билгеләнештәге биналарда, корылмаларда, шулай ук мәгариф оешмаларының дини йолалар уздыру өчен элек-электән файдаланыла торган бүлмәләрендә уздырылырга мөмкин.»;

6) 22 статьяның 2 пунктында «белем бирү һәм башка төрле учреждениеләр» сүзләрен «мәгариф һәм башка оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

7) 30 статьяның 4 пунктындагы өченче абзацында «белем бирү учреждениеләренә» сүзләрен «мәгариф оешмаларына» сүзләренә алмаштырырга.

**11 статья**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1 (1); 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3, № 6 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш), № 11 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $5^1$ статьяда:

а) 1 пунктта «яңадан һөнәри әзерлек уза» сүзләрен «һөнәри яңадан әзерлек программасы буенча укып ала» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җәмәгать судьясы вазыйфасына беренче мәртәбә сайланган җәмәгать судьясы судьяларга өстәмә белем бирә торган югары белем мәгариф оешмаларында һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларында (алга таба – мәгариф оешмалары) һөнәри яңадан әзерлек программасы буенча, шул исәптән җәмәгать судьясында стажировка узу рәвешендә, шушы чорга җәмәгать судьяларының айлык акчалата түләве, квартал саен акчалата кызыксындыру, хезмәт өчен түләү фонды акчалары исәбеннән бирелә торган башка түләүләр сакланган килеш укып ала. Элек судья вазыйфасын биләгән затлар һөнәри әзерлек программасы буенча укудан азат ителә.»;

в) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Беренче мәртәбә вазыйфасына сайланган җәмәгать судьясын мәгариф оешмаларында һөнәри яңадан әзерлек программасы буенча укытуның гомуми дәвамлылыгы алты айдан артык була алмый. Һөнәри әзерлекнең төгәл сроклары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендәге вәкаләтле органы белән тиешле шартнамә төзегән мәгариф оешмасының уку-укыту программасы нигезендә билгеләнә.»;

г) 5 пунктта «Укыту рәвешендә яңадан һөнәри әзерлек узу турындагы» сүзләрен «Мәгариф оешмасында һөнәри яңадан әзерлек программасы буенча уку турындагы» сүзләренә алмаштырырга;

д) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Беренче мәртәбә вазыйфасына сайланган җәмәгать судьясының яңадан һөнәри әзерлегенә Татарстан Республикасы территориясендә суд эшчәнлеген башкаручы җәмәгать судьясында стажировка да керә.»;

2) $5^2$ статьяда:

а) 1 пунктта «мәгариф учреждениеләрендә укыту һәм (яисә) судта стажировка рәвешләрендә» сүзләрен «мәгариф оешмаларында, шул исәптән судта стажировка рәвешендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җәмәгать судьясы квалификациясен арттыру мәгариф оешмасының уку-укыту программасы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

в) 4 пунктта «укыту рәвешендә» сүзләрен төшереп калдырырга, «мәгариф учреждениесенең уку-укыту программалары (планнары) нигезендә билгеләнә» сүзләрен «мәгариф оешмасының уку-укыту программалары нигезендә билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 һәм 6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Мәгариф оешмасында квалификация арттыру программасы буенча уку турында документның күчермәсе җәмәгать судьясы тарафыннан Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсенең кадрлар хезмәтенә тапшырыла.

6. Җәмәгать судьясының квалификациясен арттыруга шулай ук судтагы стажировка да керә.»;

д) 7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

**12 статья**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2003 елның 9 августындагы 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктында «учреждениеләренә» сүзен «оешмаларына» сүзенә алмаштырырга;

2) 25 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен өстәмә һөнәри программаларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә.».

**13 статья**

«Татарстан Республикасында милли-мәдәни автономияләр турында» 2003 елның 12 маендагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5; 2005, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның беренче өлешендәге 6 пунктында «мәгариф һәм фән учреждениеләре» сүзләрен «хосусый мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2) 10 статьяда:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кирәк булганда, дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында милли (туган) телдә укыта торган төркемнәр төзүне, дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында шундый ук сыйныфлар яисә уку төркемнәре төзүне тәэмин итәләр;»;

б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«милли-мәдәни автономияләр тәкъдимнәрен, үзләрен аерым этник төркемгә кертеп карый торган Россия Федерациясе гражданнарының яшәү урыннарын һәм башка шартларны исәпкә алып, милли (туган) телдә, милли (туган) телне, милләт тарихын һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәтеп, рус телендә белем бирә торган дәүләт мәгариф оешмалары, шулай ук милли (туган) телләрне һәм милли мәдәниятләрне өйрәнү өчен өстәмә белем бирү оешмалары (якшәмбе мәктәпләре, факультативлар, мәдәни-мәгариф үзәкләре һәм башка мәгариф оешмалары) төзиләр;»;

в) дүртенче абзацта «укыту программалары» сүзләрен «уку-укыту программалары» сүзләренә алмаштырырга;

3) 11 статьяда:

а) өченче абзацта:

«дәүләт» сүзен «федераль дәүләт» сүзләренә алмаштырырга;

«учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

б) алтынчы абзацта «дәүләтнеке булмаган (иҗтимагый) учреждениеләрен төзүдә, иҗади хезмәткәрләр һәм башка белгечләр әзерләү буенча дәүләтнеке булмаган (иҗтимагый) мәгариф учреждениеләрен ачуда» сүзләрен «дәүләтнеке булмаган (иҗтимагый) учреждениеләрен, иҗади хезмәткәрләр һәм башка белгечләр әзерләү буенча хосусый мәгариф оешмаларын төзүдә» сүзләренә алмаштырырга.

**14 статья**

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (I өлеш); 2005, № 12 (I өлеш); 2007, № 12 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) тугызынчы абзацта «ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен учреждениеләргә» сүзләрен «ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларга» сүзләренә һәм «тәрбия учреждениеләренә, шул исәптән гаилә тибындагы балалар йортларына, дәвалау учреждениеләренә, халыкны социаль яклау учреждениеләренә һәм шуңа охшаш бүтән учреждениеләргә» сүзләрен «мәгариф оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына, шуңа охшаш башка оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга;

2) егерменче абзацта «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга.

**15 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; Ватаным Татарстан, 2014, 16 апрель) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта:

а) беренче абзацта «Белем бирү учреждениеләрендә укучы» сүзләрен «Дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары буенча белем алучы» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта «урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләренә керүгә әзерлек курсларында» сүзләрен «югары белем мәгариф оешмаларының әзерлек бүлекләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«квалификацияле эшчеләр әзерләү программасы буенча түләүсез беренче һәм икенче урта һөнәри белем алу.»;

2) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Белем бирү эшчәнлеге белән шөгыльләнүче оешмаларны Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары буенча укып тәмамлаучылар – ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбеннән булган затлар, Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары буенча укуларын көндезге бүлектә дәвам итүче затлардан гайре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кием-салым, аяк киеме, йомшак инвентарь, җиһазлар һәм бер мәртәбә бирелә торган акчалата пособие белән тәэмин ителә.»;

3) 4 пунктта:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем оешмаларында дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбеннән булган затларга, тулы дәүләт тәэминатыннан тыш, социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:»;

б) икенче абзацта «әлеге белем бирү учреждениесендә» сүзләрен «әлеге мәгариф оешмасында» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче абзацта «белем бирү учреждениесеннән» сүзләрен «мәгариф оешмасыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) 6 пунктның алтынчы абзацында «гомуми белем учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем учреждениеләрендә» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

5) 7 пунктта:

а) өченче абзацта «гомуми белем бирү учреждениесендә укучыга» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмасында белем алучыга» сүзләренә алмаштырырга;

б) алтынчы абзацта «хәрби һөнәри белем бирү учреждениесендә» сүзләрен «хәрби һөнәри белем бирү оешмасында һәм югары белем хәрби белем бирү оешмасында» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 пунктта бишенче абзацта «гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларга» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларга» сүзләренә алмаштырырга.

**16 статья**

«Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы бишенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 2 (I өлеш); 2010, № 3), «башлангыч, урта һөнәри һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләрендә» сүзләрен «һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем мәгариф оешмаларында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**17 статья**

«Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» 2005 елның 1 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11; 2007, № 11; 2008, № 6), «учреждениеләрдә» сүзен «оешмаларда» сүзенә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**18 статья**

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 3; 2013, № 5; Ватаным Татарстан, 2014, 17 май) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның 1 өлешендә «учреждениеләрне» сүзен «оешмаларны» сүзенә алмаштырырга, «коткаручыларны әзерләү

һәм һәлакәттән коткару эшләрен уздыруга аттестацияләү программалары буенча өйрәтелгәннән соң» сүзләрен «коткаручыларны һөнәри әзерлек программасы буенча һөнәргә өйрәткәннән соң аттестацияләү һәм һәлакәттән коткару эшләрен уздыруга аттестацияләү нәтиҗәләре буенча» сүзләренә алмаштырырга;

2) 16 статьяның 1 һәм 3 өлешләрендә «(23 яшькә кадәр – укучы балаларына)» сүзләрен «(белем алучы 23 яшькә кадәрге балаларына)» сүзләренә алмаштырырга.

**19 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 5 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2014, 17 май), «барлык төрдәге һәм рәвештәге белем бирү учреждениеләрендә көндезге бүлектә укучы балалары (өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләреннән гайре)» сүзләрен «белем бирү эшчәнлеге белән шөгыльләнүче оешмаларда (өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларыннан тыш) төп уку-укыту программалары буенча көндезге бүлектә укучы балалары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**20 статья**

«Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 5; 2010, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның 1 һәм 2 өлешләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Коррупциягә каршы белем бирү коррупциячел хокук бозуларны ачыклау һәм профилактикалау буенча белемнәр, осталык, күнекмәләр алу һәм компетенцияне өйрәнү, җәмгыятьтә коррупция күренешләренә карата килешмәүчән мөнәсәбәт булдыру, хокукый аң һәм хокукый культура дәрәҗәсен арттыру максатларында өстәмә белем бирү программалары буенча укыту юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Коррупциягә каршы белем бирүне оештыру Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органына йөкләнә һәм аның тарафыннан законнар нигезендә Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыручы органнар һәм оешмалар белән хезмәттәшлек итеп башкарыла.»;

2) 16 статьяда:
а) 1 өлештә «учреждениеләре» сүзен төшереп калдырырга;
б) 2 өлештә «учреждениеләре» сүзен төшереп калдырырга.

**21 статья**

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8; 2012, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:
а) 2 пунктта «һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация арттыру» сүзләрен «һөнәри уку узу һәм өстәмә һөнәри белем алу» сүзләренә алмаштырырга;
б) 4 пунктта «һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация арттыру» сүзләрен «һөнәри уку узу һәм өстәмә һөнәри белем алу» сүзләренә алмаштырырга;

2) $2^1$ статьяда:
а) 3 өлештә:
1 пунктта:
икенче абзацта «һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү узган» сүзләрен «һөнәри уку узган яисә өстәмә һөнәри белем алган» сүзләренә алмаштырырга;
өченче абзацта «һөнәри әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм квалификация күтәрүгә» сүзләрен «һөнәри уку узуга яисә өстәмә һөнәри белем алуга» сүзләренә алмаштырырга;
дүртенче абзацта «һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү өчен» сүзләрен «һөнәри уку узу яисә өстәмә һөнәри белем алу өчен» сүзләренә алмаштырырга;
алтынчы абзацта «һөнәри әзерләүне, яңадан әзерләүне һәм аларның квалификацияләрен күтәрүне» сүзләрен «һөнәри укытуны яисә аларның өстәмә һөнәри белем алуын» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«эш бирүченең инвалид балаларны тәрбияләүче ата-аналарны, күпбалалы ата-аналарны эшкә урнаштыру өчен эш урыны (шул исәптән өйдә эшләү рәвешендә) булдыру (җиһазлау) чыгымнарын каплау тәртибен;»;

б) 4 өлештә:

6 пунктта:

бишенче абзацта «һөнәргә өйрәтү» сүзләрен «һөнәри уку узу һәм өстәмә һөнәри белем алу» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификацияләрен күтәрү» сүзләрен «һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлап, беренче тапкыр эш эзләүче» сүзләрен «урта һөнәри белеме булган һәм беренче мәртәбә эш эзләүче» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү узган» сүзләрен «һөнәри уку узган яисә өстәмә һөнәри белем алган» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификацияләрен күтәрү өчен» сүзләрен «һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү өчен» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыру һәм дәүләт идарәсен гамәлгә ашыру функцияләрен башкаручы органнары Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген яңадан дәвам итәргә теләүче гражданнарны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештырырга, шулай ук эшләмәүче күпбалалы ата-аналарның, инвалид балаларны тәрбияләүче ата-аналарның балаларын тәрбияләү вазыйфаларын хезмәт эшчәнлеге белән бергә алып бару өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыруны башкарырга хокуклы.».

**22 статья**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 4 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2012, № 3, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) өченче абзацта «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырырга;

2) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«һөнәри белем яисә өстәмә һөнәри белем алганда уку-укыту программаларына гигиена белеме турында бүлекләр кертү юлы белән;».

**23 статья**

«Инвалидлар һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 пунктындагы тугызынчы абзацында «башлангыч һәм урта һөнәри белем учреждениеләренең чыгарылыш укучылары арасыннан беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге гражданнар» сүзләрен «урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән алып 20 яшькә кадәрге гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында «гражданнарны яңа һөнәргә өйрәтүне» сүзләрен «гражданнарга өстәмә һөнәри белем бирүне» сүзләренә алмаштырырга.

**24 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (X өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2012, № 1, № 9) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешендәге «г» пунктының бишенче абзацында «мәгариф учреждениеләрендә һәм башка учреждениеләрдә, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә» сүзләрен «мәгариф оешмаларында һәм башка оешмаларда, шул

исәптән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 10 статьяда:

а) «д» пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«стипендияләр, шул исәптән студентларга дәүләт академик стипендиясе, студентларга дәүләт социаль стипендиясе, бюджет ассигнованиеләре хисабына көндезге уку бүлегендә белем алучы аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясе, мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән стипендияләр һәм акчалата түләүләр;»;

б) «ж» пунктының уналтынчы абзацында «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырырга;

3) 11 статьяның 3 өлешендәге икенче абзацында «профессиональ белем бирүнең хәрби белем бирү учреждениеләрендә» сүзләрен «хәрби һөнәри мәгариф оешмаларында һәм югары белем хәрби мәгариф оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 12 статьяның 1 өлешендәге икенче абзацының беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урта һөнәри яисә югары белем мәгариф оешмаларында белем алучылардан тыш, хисап чоры дәвамында керемнәре булмаган дип танылган хезмәткә сәләтле балигъ булган гражданнар гаилә әгъзаларының гомуми составыннан төшереп калдырыла.».

5) 13 статьяда:

а) 1 өлештә «учреждениеләрдә, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә» «сүзләрен «оешмаларда, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында» сүзләренә һәм «күрсәтелгән учреждениеләрдә» сүзләрен «күрсәтелгән оешмаларда» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «һөнәри белем бирүнең хәрби белем бирү учреждениеләрендә» сүзләрен «хәрби һөнәри мәгариф оешмаларында һәм югары белем хәрби мәгариф оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга.

**25 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 68 статьяның тугызынчы абзацында «уку йортлары һәм мәгариф, мәдәният, фән мәсьәләләрен алып баручы оешмалар һәм учреждениеләр» сүзләрен «белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, фәнни оешмалар, мәдәният оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 69 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«69 статья. **Экологик белем бирү системасы**

Экологик белем бирүгә, гомуми һәм комплекслы белем системасы буларак, түбәндәгеләр керә:
гомуми белем бирү;
урта һөнәри белем бирү;
югары белем бирү;
өстәмә һөнәри белем бирү;
экологик белемнәрне тарату, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары, музейлар, китапханәләр, мәдәният учреждениеләре, табигатьне саклау учреждениеләре, спорт һәм туристлык оешмалары аша.»;

3) 70 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«70 статья. **Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда экологик белем**

Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда экологик белем бирү федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4) 71 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 73 статьяның 2 өлешендәге беренче абзацында «мәгариф учреждениеләре» сүзләрен «белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга.

**26 статья**

«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, 12) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 өлешендә «уку» сүзен «белем алу» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктта «махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләрендә» сүзләрен «тәрбия, белем бирүнең махсус шартларына мохтаҗ һәм махсус педагогик мөнәсәбәт таләп итүче девиант холыклы (җәмгыять өчен куркыныч) белем алучылар өчен мәгариф оешмаларында (ачык һәм ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләрендә)» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта «учреждениеләреннән» сүзен «оешмаларыннан» сүзенә алмаштырырга;

11 пунктта «укудан» сүзен «белем алудан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлештә «мәгариф учреждениеләренең» сүзләрен «мәгариф оешмаларының» сүзләренә алмаштырырга;

3) 4 статьяда:

а) 3 пунктта «гомуми белем бирү учреждениесенә» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмасына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктта «гомуми белем бирү учреждениесенә йөрүдән» сүзләрен «мәгариф оешмасында белем алудан» сүзләренә алмаштырырга;

в) 6 пунктта «укуын» сүзен «белем алуын» сүзләренә алмаштырырга;

4) 5 статьяда:

а) 1 пунктта «уку» сүзен «белем алу» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктта «укуын дәвам итүдә» сүзләрен «югарырак баскычта белем алуда» сүзләренә алмаштырырга;

5) 6 статьяда:

а) 1 өлештә «уку» сүзен «белем алу» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «уку» сүзен «белем алу» сүзләренә алмаштырырга.

**27 статья**

«Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2012, № 12 (I өлеш); 2013, 12 (I өлеш), «балалар тәүлек буе була торган мәгариф учреждениеләре» сүзләрен «интернаты булган

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**28 статья**

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 8 – 9; 2012 № 1; Ватаным Татарстан, 2014, 17 май) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында «тикшеренү лабораторияләреннән, мәгариф учреждениеләреннән һәм үзәкләреннән,» сүзләрен «фәнни оешмалардан, лабораторияләрдән, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалардан, шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 статьяның 5 пунктында «фәнни-мәгариф» сүзләрен «белем бирү» сүзләренә алмаштырырга.

**29 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $19^3$ статьясындагы 6 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; Ватаным Татарстан, 2014, 17 май), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«6) мәгариф оешмалары;».

**30 статья**

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 5; 2013, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9) мәгариф өлкәсендә идарәне башкаручы органның гомуми белем алмаган балигъ булмаганнарны мәгариф оешмасыннан

чыгару турындагы һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда аларны укытуның башка мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрен карый.»;

2) түбәндәге эчтәлекле яңа 22[1] пункт өстәргә:

«22[1]) унбиш яше тулган балигъ булмаган белем алучы төп гомуми белем алганчы ук аның гомуми белем бирү оешмасыннан китүенә ризалык бирәләр һәм балигъ булмаганның белем алуның башка рәвешендә төп гомуми белемнең уку-укыту программасын үзләштерүен дәвам итү һәм аның ризалыгы белән эшкә урнаштыру буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта чаралар күрәләр;».

**31 статья**

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8; 2013, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктта «белем бирү учреждениеләренә, мәгариф идарәсе органнарының ачык һәм ябык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениеләренә, балаларга медицина ярдәме күрсәтә торган сәламәтлек саклау учреждениеләренә» сүзләрен «белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга; тәрбия, белем бирүнең махсус шартларына мохтаҗ һәм махсус педагогик мөнәсәбәт таләп итүче девиант холыклы (җәмгыять өчен куркыныч) белем алучылар өчен мәгариф оешмаларына (ачык һәм ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләренә); балаларга медицина ярдәме күрсәтә торган медицина оешмаларына» сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 пунктта «фәнни учреждениеләргә» сүзләрен «фәнни оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга.

**32 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» 2012 елның 14 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма

басмасы, 2012, № 7 (I өлеш), «учреждениесендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**33 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 8 пунктында «учреждениеләренә» сүзен «оешмаларына» сүзенә һәм «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырырга;

2) 15 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында «учреждениеләренә» сүзен «оешмаларына» сүзенә һәм «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырырга.

**34 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырырга;

2) 4 статьяның 2 өлешендәге 3 пунктында «югары уку йортлары» сүзләрен «югары белем мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга.

**35 статья**

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә «мәгариф учреждениеләрендә,» сүзләрен төшереп калдырырга, «халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә тора торган» сүзләрен «мәгариф оешмаларында, медицина оешмаларында, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларында яшәп тору» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда:

а) 1 өлештә «мәгариф учреждениеләрендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә» сүзләрен «мәгариф оешмаларында, медицина оешмаларында, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «мәгариф учреждениесендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениесендә» сүзләрен «мәгариф оешмасында, медицина оешмасында, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмасында» сүзләренә алмаштырырга;

**36 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2014, 17 май) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 3 пунктында «муниципаль хезмәткәрләрне һәм дәүләт граждан хезмәткәрләрен әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм аларның квалификацияләрен күтәрүгә» сүзләрен «муниципаль һәм граждан хезмәте өчен кадрлар әзерләүгә һәм өстәмә һөнәри белемгә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 17 статьяның 10 өлешендә «һәм мәгариф учреждениеләреннән,» сүзләрен «, мәгариф һәм (яисә)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 29 статьяның 2 өлешендә «яңа һөнәргә өйрәнү, квалификация күтәрү яисә стажировка узу» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алу» сүзләренә алмаштырырга;

4) 4 нче кушымтада:

а) 6 пунктның икенче абзацында «һәм мәгариф учреждениеләре,» сүзләрен «, мәгариф һәм (яисә)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 18 пунктның 3 пунктчасында «яңадан профессиональ әзерлекне уңышлы узу яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 21 пунктның 2 пунктчасында «яңадан профессиональ әзерлек узуга яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 22 пунктта «яңадан профессиональ әзерлек узудан,» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү турындагы Үрнәк нигезләмәгә кушымтада «яңадан профессиональ әзерлекне уңышлы узу һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

**37 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 12 июне
№ 53-ТРЗ

## ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

### 574. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2005, № 7 – 8; 2008, № 5 (I өлеш); 2013, № 7) үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 30 июне
№ 54-ТРЗ

# ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## 575. Татарстан Республикасының аерым закон актларына Татарстан Республикасы дәүләт граждан (муниципаль) хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) вазыйфаларын биләгән затларны пенсия белән тәэмин итү өлешендә үзгәрешләр кертү турында

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 25 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында «дәүләт пенсиясенә» сүзләрен «пенсиягә» сүзенә алмаштырырга;

2) 26 статьяда:
а) исемендә «дәүләт пенсиясенә» сүзләрен «пенсиягә» сүзенә алмаштырырга;
б) 1 өлештә:
беренче абзацта «дәүләт пенсиясенә» сүзләрен «пенсиягә» сүзенә алмаштырырга;
икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге статья максатларында тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясен алу хокукын бирүче яшькә җиткәч йә вакытыннан алда картлык буенча хезмәт пенсиясе (хезмәт пенсиясенең бер өлеше) яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгәндә һәм тиешле еллар эшләгәне өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле дәүләт хезмәте стажы булганда, әлеге Законның 45 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында каралган нигезләр буенча дәүләт хезмәтеннән китү аңлашыла.»;

в) 3 өлештә «дәүләт пенсиясенә» сүзләрен «пенсиягә» сүзенә алмаштырырга;

г) 4 өлештә «дәүләт пенсиясенә» сүзләрен «пенсиягә» сүзенә алмаштырырга;

д) 5 өлештә «дәүләт пенсиясенә» сүзләрен «пенсиягә» сүзенә алмаштырырга;

3) 32 статьяда:

1 өлешнең беренче абзацында «дәүләт пенсиясен» сүзләрен «пенсия» сүзенә алмаштырырга;

2 өлешнең беренче абзацында «дәүләт пенсиясе» сүзләрен «пенсия» сүзенә алмаштырырга;

3 өлештә «дәүләт пенсиясе» сүзләрен «пенсия» сүзенә алмаштырырга;

4) 33 статьяда:

1 өлештә «дәүләт пенсиясе», «дәүләт пенсиясен» сүзләрен «пенсия» сүзенә алмаштырырга;

7 өлештә тиешле сандагы һәм килештәге «дәүләт пенсиясе» сүзләрен тиешле сандагы һәм килештәге «пенсия» сүзенә алмаштырырга;

5) 45 статьяда:

а) исемендә «дәүләт пенсиясе» сүзләрен «пенсия» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Закон нигезендә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән дәүләт хезмәткәрләре, әлеге статьяның $1^1$, $1^2$, 2 һәм $2^1$ өлешләрендә билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып, түбәндәге шартлар үтәлгән очракта, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукына ия булалар:

1) дәүләт хезмәтендә кимендә 15 ел стажы булса;

2) әлеге Законның 32 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаларда, шулай ук әлеге статьяның $2^1$ өлеше нигезендә башка вазыйфаларда кимендә 10 ел эш (хезмәт) стажы булса;

3) Федераль законның 33 статьясындагы 1 өлешенең 1 – 3, 5, 7 – 9 пунктларында, 37 статьясындагы 1 өлешенең 1, $8^1$ – $8^3$ пунктларында, 39 статьясындагы 1 өлешенең 2 – 4 пунктларында һәм 2 өлешенең 2 – 4 пунктларында каралган нигезләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең соңгы биләгән вазыйфасыннан азат ителсә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән җибәрелсә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ өлешләр өстәргә:

«$1^1$. Дәүләт хезмәткәрләре, әгәр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасыннан азат ителгән вакытка «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясен алу хокукын бирүче яшькә җиткән булсалар йә аларга, әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, вакытыннан алда картлык буенча хезмәт пенсиясе (хезмәт пенсиясенең бер өлеше) яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгән булса, Федераль законның 33 статьясындагы 1 өлешенең 1, 2 (Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» яисә «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфасын биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең билгеләнгән вәкаләтләр чоры бетүгә бәйле рәвештә вакытлы хезмәт контрактының гамәлдә булу чоры бетү очракларыннан тыш), 3 һәм 7 пунктларында, 37 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктындагы «б» пунктчасында һәм 39 статьясындагы 2 өлешенең 4 пунктында каралган нигезләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән җибәрелгәндә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукына ия булалар.

$1^2$. Дәүләт хезмәткәрләре Федераль законның 33 статьясындагы 1 өлешенең 2 (Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» яисә «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфасын биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең билгеләнгән вәкаләтләр чоры бетүгә бәйле рәвештә вакытлы хезмәт контрактының гамәлдә булу чоры беткән очракта), 5, 8 һәм 9 пунктларында, 37 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктындагы «а» пунктчасында һәм $8^1$ – $8^3$ пунктларында, 39 статьясындагы 1 өлешенең 2 – 4 пунктларында һәм 2 өлешенең 2 һәм 3 пунктларында каралган нигезләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән җибәрелгәндә, җибәрелгән вакытка картлык (инвалидлык) буен-

ча хезмәт пенсиясенә хокук бирелүгә карамастан, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукына ия булалар.»;

г) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәткәрләре «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясен алу хокукын бирүче яшькә җиткәнче йә вакытыннан алда картлык буенча хезмәт пенсиясе (хезмәт пенсиясенең бер өлеше) яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгәнче Федераль законның 33 статьясындагы 1 өлешенең 1, 2 (Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» яисә «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфасын биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең билгеләнгән вәкаләтләр чоры бетүгә бәйле рәвештә вакытлы хезмәт контрактының гамәлдә булу чоры бетү очракларыннан тыш), 3 һәм 7 пунктларында, 37 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктындагы «б» пунктчасында каралган нигезләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән җибәрелгәндә, аларның әлеге Законның 32 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаларда, шулай ук әлеге статьяның $2^1$ өлеше нигезендә башка вазыйфаларда кимендә 15 ел эш (хезмәт) стажы булу шарты белән, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукына ия булалар.»;

д) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында һәм 2 өлешендә күрсәтелгән эш (хезмәт) стажына шулай ук әлеге Законның 32 статьясындагы 1 өлешенең 2, 7, 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән вазыйфаларда Татарстан Республикасында эшләү (хезмәт итү) чорлары, әгәр бу чорлар әлеге Законның 32 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаларда турыдан-туры эшкә (хезмәткә) кадәр һәм (яисә) турыдан-туры аннан соң булса, гомуми дәвамлылыгы 5 елдан арттырылмыйча кертелә. Бу чакта әлеге Законның 32 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаларда эшкә (хезмәткә) кадәр яисә эштән (хезмәттән) соң эзлекле рәвештә әлеге Законның 32 статьясындагы 1 өлешенең 2, 7, 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән вазыйфаларда эшләү (хезмәт итү) чорлары барысы да исәпкә алына.»;

е) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясен алу хокукын бирүче яшькә җиткәч йә вакытыннан алда картлык буенча хезмәт пенсиясе (хезмәт пенсиясенең бер өлеше) яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгән

вакытта билгеләнә. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия гомер буена билгеләнә һәм ай саен түләнә.»;

ж) 10 өлештә «көннән һәм «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык (инвалидлык) буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгән көннән соңгы көннән» сүзләрен «һәм әлеге статьяның 3 өлешендә каралган шартлар үтәлгән көннән соң килә торган көннән» сүзләренә алмаштырырга;

з) 13 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Бер үк вакытта әлеге Закон нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең башка субъектлары законнары, җирле үзидарә органнары актлары нигезендә федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Россия Федерациясенең башка субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар акчалары исәбеннән билгеләнә һәм финанслана торган федераль дәүләт граждан хезмәткәре яисә муниципаль хезмәткәр буларак тиешле еллар эшләгән өчен пенсия, тиешле еллар эшләгән өчен башка нигезләр буенча пенсия, гомере буена айлык акчалата түләү алу, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын яисә Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны биләгән затларның пенсиясенә айлык өстәмә, өстәмә рәвештә (гомере буена) айлык матди тәэмин ителү, инвалидлык буенча пенсия (инвалидлык буенча хезмәт пенсиясеннән тыш), картлык (инвалидлык) буенча хезмәт пенсиясенә (хезмәт пенсиясенең бер өлешенә) айлык башка өстәмә алу хокукына ия дәүләт хезмәткәренә әлеге Закон нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия түләнә яисә, федераль законнарда башкасы каралмаган булса, аның теләге буенча бүтән түләү бирелә.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 4 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләгән һәм бер үк вакытта әлеге Закон нигезендә пенсиягә өстәмә түләү алу һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законна-

ры, Россия Федерациясенең башка субъектлары законнары, җирле үзидарә органнары актлары нигезендә федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Россия Федерациясенең башка субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар акчалары исәбеннән билгеләнә һәм финанслана торган Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны биләгән затларның пенсиясенә айлык өстәмә, дәүләт граждан хезмәткәре яисә муниципаль хезмәткәр буларак тиешле еллар эшләгән өчен пенсия, тиешле еллар эшләгән өчен башка нигезләр буенча пенсия, гомере буена айлык тәэмин ителү, өстәмә рәвештә (гомере буена) айлык матди тәэмин ителү, инвалидлык буенча пенсия (инвалидлык буенча хезмәт пенсиясеннән тыш), картлык (инвалидлык) буенча хезмәт пенсиясенә (хезмәт пенсиясенең бер өлешенә) айлык башка өстәмәләр алу хокукына ия затка әлеге Закон нигезендә пенсиягә өстәмә түләнә яисә, федераль законнарда башкасы каралмаган булса, аның теләге буенча бүтән түләү бирелә.».

### 3 статья

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) беренче абзацта «дәүләт пенсиясенә өстәмә (алга таба – пенсиягә өстәмә)» сүзләрен «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон) нигезендә билгеләнгән картлык (инвалидлык) буенча хезмәт пенсиясенә айлык өстәмә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясе алуга хокук бирүче яшькә җитү йә вакытыннан алда картлык буенча хезмәт пенсиясе (хезмәт пенсиясенең бер өлеше) яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнсә.»;

2) түбәндәге эчтәлекле 8[1] өлеш өстәргә:

«8[1]. Пенсиягә өстәмә билгеләүне сорап мөрәҗәгать итү көненә муниципаль вазыйфа, шул исәптән муниципаль берәмлек үзгәртеп төзелүгә бәйле рәвештә бетерелгән очракта, пенсиягә өстәмәне исәпләп чыгару бу муниципаль берәмлектә шундый ук йә аңа тиңләштерелгән муниципаль вазыйфаның айлык акчалата түләү күләменнән, ә тиешле вазыйфа булмаган очракта – җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгели торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты нигезендә хезмәт өчен түләүнең шул ук төркеменә кертелгән башка муниципаль берәмлектә шундый ук йә аңа тиңләштерелгән муниципаль вазыйфаның айлык акчалата түләү күләменнән исәпләп чыгарыла. Муниципаль вазыйфаларның тәңгәллеген билгеләү Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү өчен каралган тәртиптә башкарыла.»;

3) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләгән һәм бер үк вакытта әлеге Закон нигезендә пенсиягә өстәмә һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектлары законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Россия Федерациясенең башка субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар акчалары исәбеннән билгеләнә һәм финанслана торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затларның пенсиясенә айлык өстәмә, дәүләт граждан хезмәткәре яисә муниципаль хезмәткәр буларак тиешле еллар эшләгән өчен пенсия, тиешле еллар эшләгән өчен башка нигезләр буенча пенсия, гомере буена айлык акчалата түләү алу, өстәмә рәвештә (гомере буена) айлык матди тәэмин ителү, инвалидлык буенча пенсия (инвалидлык буенча хезмәт пенсиясеннән тыш), картлык (инвалидлык) буенча хезмәт пенсиясенә (хезмәт пенсиясенең бер өлешенә) айлык башка өстәмә алу хокукына ия затка әлеге Закон нигезендә пенсиягә өстәмә түләнә яисә, федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, аның үз теләге буенча башка түләү бирелә.».

**4 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма

басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2014, 17 май) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарында, муниципаль органнарда (алга таба – җирле үзидарә органнары) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән муниципаль хезмәткәрләр әлеге Кодекс нигезендә, бу статьяның $1^1$, $1^2$, 2 һәм $2^1$ өлешләрендә билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып, түбәндәге шартлар үтәлгән очракта, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия (алга таба – тиешле еллар эшләгән өчен пенсия) алу хокукына ия:

1) кимендә 15 ел муниципаль хезмәт стажы булса;

2) әлеге Кодексның 29 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында, 2 өлешенең 3 пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән вазыйфаларда, шулай ук әлеге статьяның $2^1$ өлеше нигезендә башка вазыйфаларда кимендә 10 ел эш (хезмәт) стажы булса;

3) Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең соңгы биләгән вазыйфасыннан азат ителүе һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттән җибәрелүе түбәндәгеләрдә каралган нигезләр буенча булса:

а) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 19 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 3 пунктларында (муниципаль хезмәткәр үз көченә кергән суд карары белән хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикле дип танылган очракта);

б) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешенең 1 – 3, 5 (дәүләт хезмәтенә күчерелгән яисә сайланулы эшкә (вазыйфага) күчкән очракта), 7 – 9 пунктларында, 81 статьясындагы беренче өлешенең 1 – 3 пунктларында, 83 статьясындагы беренче өлешенең 2, 5 һәм 7 пунктларында.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ өлешләр өстәргә:

«$1^1$. Муниципаль хезмәткәрләр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 19 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешенең 1, 2 (муниципаль хезмәткәр биләгән вазыйфа муниципаль вазыйфаны биләгән зат вәкаләтләренең үтәлешен турыдан-туры тәэмин итү өчен булдырылып, муниципаль вазыйфаны биләгән затның билгеләнгән вәкаләтләр срогы тәмамлануга бәйле рәвештә хезмәт шартнамәсе срогы бетү очракларыннан тыш), 3 һәм 7 пунктларында, 81 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктын-

да каралган нигезләр буенча Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттән җибәрелгәндә, алар Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителү вакытына «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясен алу хокукын бирүче яшькә җиткән булсалар йә аларга вакытыннан алда картлык буенча хезмәт пенсиясе (хезмәт пенсиясенең бер өлеше) яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгән булса, әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукына ия булалар.

$1^2$. Муниципаль хезмәткәрләр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 19 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында (муниципаль хезмәткәр үз көченә кергән суд карары белән хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикле дип танылган очракта), Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешенең 2 (муниципаль хезмәткәр биләгән вазыйфа муниципаль вазыйфаны биләгән зат вәкаләтләренең үтәлешен турыдан-туры тәэмин итү өчен булдырылып, муниципаль вазыйфаны биләгән затның билгеләнгән вәкаләтләр срогы тәмамлануга бәйле рәвештә хезмәт шартнамәсе срогы беткән очракта), 5 (дәүләт хезмәтенә күчерелгән яисә сайланулы эшкә (вазыйфага) күчкән очракта), 8 һәм 9 пунктларында, 81 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларында, 83 статьясындагы беренче өлешенең 2, 5 һәм 7 пунктларында каралган нигезләр буенча Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттән җибәрелгәндә, җибәрелү вакытына картлык буенча (инвалидлык буенча) хезмәт пенсиясен алу хокукы булу-булмауга бәйсез рәвештә, тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт пенсиясе алу хокукына ия булалар.»;

3) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәткәрләр «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәнче йә вакытыннан алда картлык буенча хезмәт пенсиясе (хезмәт пенсиясенең бер өлеше) яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгәнче Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешенең 2 (муниципаль хезмәткәр биләгән вазыйфа муниципаль вазыйфаны биләгән зат вәкаләтләренең үтәлешен турыдан-туры тәэмин итү өчен булдырылып, муниципаль вазыйфаны биләгән затның билгеләнгән вәкаләтләр срогы тәмамлануга бәйле рәвештә хезмәт шартнамәсе срогы беткән очракта), 5 (дәүләт хезмәтенә

күчерелгән яисә сайланулы эшкә (вазыйфага) күчкән очракта), 8 һәм 9 пунктларында, 81 статьясындагы беренче өлешенең 1, 2 пунктларында, 83 статьясындагы беренче өлешенең 2, 5 һәм 7 пунктларында каралган нигезләр буенча Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттән җибәрелгәндә, әлеге Кодексның 29 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында, 2 өлешенең 3 пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән вазыйфаларда, шулай ук әлеге статьяның $2^1$ өлеше нигезендә башка вазыйфаларда кимендә 15 ел эш (хезмәт) стажы булган очракта, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукына ия булалар.»;

4) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында, 2 өлешендә күрсәтелгән эш (хезмәт) стажына шулай ук әлеге Кодексның 29 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 11 пунктларында, 2 өлешенең 1, 2 пунктларында, 3 пунктының «а» – «д», «ж» һәм «з» пунктчаларында күрсәтелгән вазыйфаларда Татарстан Республикасында эшләү (хезмәт итү) чорлары, әгәр бу чорлар әлеге Кодексның 29 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында, 2 өлешенең 3 пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән вазыйфаларда турыдан-туры эшкә (хезмәткә) кадәр һәм (яисә) турыдан-туры аннан соң булса, гомуми дәвамлылыгы биш елдан арттырылмыйча кертелә. Бу чакта әлеге Кодексның 29 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында, 2 өлешенең 3 пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән вазыйфаларда эшкә (хезмәткә) кадәр яисә эштән (хезмәттән) соң өзлекле рәвештә биләнә торган, әлеге Кодексның 29 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 11 пунктларында, 2 өлешенең 1, 2 пунктларында һәм 3 пунктының «а» – «д», «ж» һәм «з» пунктчаларында күрсәтелгән вазыйфаларда эшләү (хезмәт итү) чорлары барысы да исәпкә алына.»;

5) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясен алу хокукы бирә торган яшькә җиткәч йә вакытыннан алда картлык буенча хезмәт пенсиясе (хезмәт пенсиясенең бер өлеше) яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгән вакытта билгеләнә. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия гомер буена билгеләнә һәм ай саен түләнә.»;

6) 14 өлештә «һәм «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык (инвалидлык) буен-

ча хезмәт пенсиясе билгеләнгән» сүзләрен «һәм әлеге статьяның 3 өлешендә каралган шартлар үтәлгән» сүзләренә алмаштырырга;

7) 17 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«17. Әгәр башкасы федераль законнарда каралмаган булса, бер үк вакытта әлеге Кодекс нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектлары законнары, җирле үзидарә органнары актлары нигезендә федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Россия Федерациясенең башка субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар акчалары исәбеннән билгеләнә һәм финанслана торган дәүләт граждан хезмәткәре буларак тиешле еллар эшләгән өчен пенсия, тиешле еллар эшләгән өчен башка нигезләр буенча пенсия, гомере буена айлык акчалата түләү алу, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын яисә Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны биләгән затларның пенсиясенә айлык өстәмә алу, өстәмә рәвештә (гомере буена) айлык матди тәэмин ителү, инвалидлык буенча пенсия (инвалидлык буенча хезмәт пенсиясеннән тыш), картлык (инвалидлык) буенча хезмәт пенсиясенә (хезмәт пенсиясенең бер өлешенә) башка өстәмә алу хокукына ия муниципаль хезмәткәргә әлеге Кодекс нигезендә пенсиягә өстәмә түләнә яисә аның үз теләге буенча башка түләү бирелә.».

**5 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң утыз көн узгач үз көченә керә.

2. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергәнче дәүләт хезмәтен туктаткан (вазыйфадан җибәрелгән, азат ителгән) затларның «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (әлеге Закон редакциясендә) нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукы «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 33 статьясындагы 1 өлешенең 1 – 3, 5, 7 – 9 пунктларында, 37 статьясындагы 1 өлешенең 1, $8^1$ – $8^3$ пунктларында, 39 статьясындагы 1 өлешенең 2 – 4 пунктларында һәм 2 өлешенең 2 – 4 пунктларында каралган дәүләт хезмәтен туктату (вазыйфадан җибәрелү, азат ителү) нигезләренә туры килә торган нигезләрдән чыгып билгеләнә.

3. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Рес-

публикасы Законының 32 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, башка вазыйфаларны, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән, күрсәтелгән вазыйфалардан әлеге Закон үз көченә кергәнче җибәрелгән һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләнмәгән затларга тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү, әлеге статьяның 4 һәм 5 өлешләрендә билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (әлеге Закон редакциясендә), Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы (әлеге Закон редакциясендә) нигезендә башкарыла.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән затлар, дәүләт (муниципаль) хезмәтенең тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен түбәндәге таләпләрнең кайсына да булса туры килә торган стажы булу шарты белән, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукына ия:

1) «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктлары, 2 и $2^{1}$ өлешләре (әлеге Закон редакциясендә), Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктлары, 2 и $2^{1}$ өлешләре (әлеге Закон редакциясендә) нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен дәүләт (муниципаль) хезмәте стажы булу;

2) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән (Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттән) җибәрелгән көнгә кимендә 15 ел дәүләт (муниципаль) хезмәте стажы булу (үз теләге белән эштән киткән затлар өчен);

3) кимендә 15 ел дәүләт (муниципаль) хезмәте стажы булу (әлеге өлешнең 2 пунктында күрсәтелгән затлардан тыш, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты (әлеге Закон редакциясендә), Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты (әлеге Закон редакциясендә) һәм әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукы бирә торган нигезләр буенча җибәрелгән затлар өчен).

5. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45 статьясындагы $1^{1}$ һәм $1^{2}$ өлешләре (әлеге Закон редакциясендә), Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясындагы $1^{1}$

һәм 1[2] өлешләре (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләренең гамәли көче, әлеге Закон үз көченә кергәч, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттән җибәрелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә кагыла.

6. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты (әлеге Закон редакциясендә), Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләренең гамәли көче әлеге Закон үз көченә кергән көнгә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттә булган һәм 50 яшькә (ир-атлар өчен) һәм 45 яшькә (хатын-кызлар өчен) җиткән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә кагылмый.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары үз норматив хокукый актларын әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып ике ай эчендә әлеге Законга туры китерергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 30 июне
№ 55-ТРЗ

## ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

### 576. Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 110 һәм 114 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш);

2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 110 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«110 статья. **Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны ачыклау һәм исәпкә алу**

1. Оешмаларның (мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының, гомуми белем бирү оешмаларының, медицина оешмаларының һәм башка оешмаларның) әлеге Кодексның 109 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән балалар турында белешмәләрдән хәбәрдар булган вазыйфаи затлары һәм бүтән гражданнар бу хакта балалар фактта булган урындагы опека һәм попечительлек органнарына хәбәр итәргә тиеш.

2. Опека һәм попечительлек органы мондый белешмәләр алган көннән алып өч эш көне дәвамында баланың яшәү шартларын тикшерүне уздырырга һәм, ата-анасының яисә туганнарының аны тәрбияләмәү факты билгеләнгәндә, баланы урнаштыру мәсьәләсе хәл ителгәнгә кадәр аның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итәргә, шулай ук бу бала турында булган мәгълүматны ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар хакында республика белешмәләр банкында беренчел исәпкә алу һәм «Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкы хакында» 2001 елның 16 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында федераль белешмәләр банкында беренчел исәпкә алу өчен бер үк вакытта Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган федераль башкарма хакимият органына җибәрү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органына җибәрергә тиеш.

3. Опека һәм попечительлек органы әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр алган көннән алып бер ай дәвамында ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала турында документлаштырылган мәгълүматны ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар хакында республика белешмәләр банкында исәпкә алу, баланы Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнары гаиләсенә урнаштыруны оештыру һәм «Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкы хакында» 2001 елның 16 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында федераль белешмәләр банкында исәпкә алу өчен бер үк вакытта тиешле федераль башкарма хакимият органына җибәрү өчен Татарстан Республикасы башкарма

хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органына җибәрергә тиеш.

4. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар булган мәгариф оешмаларының, медицина оешмаларының, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның яисә шундый оешмаларның җитәкчеләре баланың гаиләгә тәрбиягә тапшырыла алуы турында үзләренә мәгълүм булган көннән алып өч эш көне дәвамында бу хакта аны гаиләгә тәрбиягә урнаштыруны оештыру өчен тиешле оешма урнашкан урындагы опека һәм попечительлек органына хәбәр итәргә тиеш.

5. Опека һәм попечительлек органы әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр кергән көннән алып бер ай эчендә баланы урнаштыруны тәэмин итә.

6. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән алып ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнары гаиләсенә урнаштыруны оештыра, ә мондый мөмкинлек булмаганда, әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән алып бер ай үткәннән соң Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеле торган федераль башкарма хакимият органы баланы Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданнары гаиләсенә тәрбиягә урнаштыруда ярдәм итә.

7. Әлеге статьяның 4 – 6 өлешләрендә каралган бурычларны үтәмәгән өчен, белә торып дөрес булмаган белешмәләр биргән өчен, баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырудан яшереп калдыруга юнәлдерелгән башка гамәлләр өчен әлеге статьяның 4 – 6 өлешләрендә күрсәтелгән оешмаларның җитәкчеләре һәм органнарның вазыйфаи затлары законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылалар.»;

2) 114 статьяның 1 өлешендә «4 – 6 өлешләрендә» сүзләрен «3 – 6 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 30 июне
№ 56-ТРЗ